# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Мәгариф турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 8 – 9; 2002, № 2; 2004, № 4 – 5; 2006, № 6 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 3 пунктында "үсешләрендә кимчелек булган" сүзләрен "сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән" сүзләренә алмаштырырга;

2) 12 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Мәгариф учреждениесенең гамәлгә куючысы (алга таба – гамәлгә куючы) түбәндәгеләр булырга мөмкин:

1) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр;

2) Россиянең һәм чит илләрнең коммерция оешмалары, шулай ук күрсәтелгән юридик затларның берләшмәләре (ассоциацияләр һәм берлекләр);

3) Россиянең һәм чит илләрнең коммерциягә карамаган оешмалары, шул исәптән иҗтимагый һәм дини оешмалар, шулай ук күрсәтелгән юридик затларның берләшмәләре (ассоциацияләр һәм берлекләр);

4) физик затлар.

Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләрен уртак гамәлгә кую рөхсәт ителә.";

б) 2 пунктта "Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм (яисә) федераль башкарма хакимият органнары" сүзләрен "Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясе" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

"$2^1$. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек тарафыннан төзелгән мәгариф учреждениесен гамәлгә куючының функцияләре һәм вәкаләтләре, әгәр федераль законнарда, Россия Федерациясе Президентының яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында башкача билгеләнмәгән булса, тиешле очракта федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары үзгәртеп корылган очракта, гамәлгә куючының хокуклары тиешле хокук дәвамчысына күчә.";

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 13 статьяда:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Мәгариф учреждениеләре дәүләт, муниципаль, дәүләткә карамаган учреждениеләр (хосусый учреждениеләр, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар учреждениеләре) булырга мөмкин.";

б) түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

"10. Мәгариф учреждениесе вәкиллекләрендә уку-укыту эшчәнлеген алып бару тыела.";

4) 14 статьяның 1 пунктындагы 6 пунктчасында:

а) "б" пунктчасында "финанслау" сүзен "финанс белән тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

б) "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"г) керем китерә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр өчен – федераль законнарга каршы килмәгән очракларда);";

в) "е" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"е) керем китерә торган эшчәнлектән алынган керемнәр исәбеннән учреждение тарафыннан сатып алынган мөлкәт белән эш итү тәртибе;";

г) "ж" пунктчасында "казначылык органнарында" сүзләрен "Федераль казначылыкның территориаль органында, Татарстан Республикасының (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең) финанс органында" сүзләренә алмаштырырга;

5) 20 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Һөнәри белем бирү программалары (шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр һәм инвалидлар өчен) һөнәри белем бирү учреждениеләрендә, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, гамәлгә ашырыла.

Дәүләт аккредитациясе булган һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре күрсәтелгән тиешле дәрәҗәдәге белем бирү программаларын, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган һөнәрләр һәм әзерләү юнәлешләре (белгечлекләр) исемлекләре нигезендә квалификацияле хезмәттә

эшләүчеләрне (эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне) һәм тиешле дәрәҗәдәге белгечләрне әзерләү максатларында гамәлгә ашыралар.

Мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан яңа һөнәрләр һәм әзерләү юнәлешләре (белгечлекләр) расланганда, аларның моңа кадәрге һөнәрләр һәм әзерләү юнәлешләре (белгечлекләр) исемлекләрендә яисә Мәгариф буенча белгечлекләрнең гомумроссия классификаторында күрсәтелгән аерым һөнәрләргә һәм әзерләү юнәлешләренә (белгечлекләргә) тәңгәллеге билгеләнә.

Мондый тәңгәллекне билгеләгәндә мәгариф учреждениесе тәңгәллек билгеләнгән һөнәрләр һәм әзерләү юнәлешләре (белгечлекләр) буенча әзерләү максатларында уку-укыту эшчәнлеген үзләренең лицензиясе һәм дәүләт аккредитациясе турындагы таныклык нигезендә аларның гамәли сроклары тәмамланганчы башкарырга хокуклы.";

6) 27 статьяның 2 пунктында "тиешле" сүзе алдыннан ", әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса," сүзләрен өстәргә;

7) 29 статьяда:

а) 1 пунктның алтынчы абзацында "мәгарифне финанслауга" сүзләрен "уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә" сүзләренә алмаштырырга;

"мәгарифне финанслауның" сүзләрен "уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүнең" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктның бишенче абзацында "финанслау" сүзен "финанс белән тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта "мәгариф учреждениеләрендә" сүзләреннән соң ", шулай ук дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү учреждениеләрендә" сүзләрен өстәргә;

8) 33 статьяның 3 пунктындагы икенче абзацында түбәндәге эчтәлекле "ж" пунктчасы өстәргә:

"ж) Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнеп куела ала.";

9) 35 статьяда:

а) 1 пунктта "җирле үзидарә органы" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе" сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктның икенче абзацында "(берләшмәләр)" сүзен һәм "(берләшмәләрнең)" сүзен төшереп калдырырга;

в) 5 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Уку-укыту эшчәнлеген алып бару хокукына лицензия биргән өчен салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә дәүләт пошлинасы түләнә.";

г) 10 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Мәгариф учреждениесен яисә фәнни оешманы дәүләт аккредитацияләве турында таныклык биргән өчен салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә дәүләт пошлинасы түләнә.";

д) 15 пунктта "җирле үзидарә органы" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе" сүзләренә алмаштырырга;

е) 16 пунктның беренче абзацында "автономияле" сүзеннән соң ", бюджет яисә казна" сүзләрен өстәргә;

ж) 18 пунктның икенче абзацында "җирле үзидарә органнары" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе" сүзләренә алмаштырырга;

10) 36 статьяның 5 – 7 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

11) 37 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"37 статья. **Уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү**";

б) 1 пунктта "Мәгариф учреждениесе эшчәнлеге законнар нигезендә финанслана" сүзләрен "Мәгариф учреждениесе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла" сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта:

беренче абзацның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт бюджет һәм автономияле мәгариф учреждениеләре тарафыннан дәүләт бурычын үтәүне финанс белән тәэмин итү – уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүнең федераль нормативлары нигезендә, Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренең уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүнең Татарстан Республикасы нормативлары нигезендә гамәлгә ашырыла.";

икенче абзацта "финанслау нормативы" сүзләрен "уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү нормативы" сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 пунктта "финанслау" сүзен "уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктта:

беренче җөмләдә "финанслау" сүзен "дәүләт учреждениеләренең уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

икенче җөмләдә "финанслау" сүзен "уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 пунктның тугызынчы абзацында "финанслау" сүзен "уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

12) 41 статьяның 3 пунктында "устав" сүзе алдыннан "Россия Федерациясе законнары һәм" сүзләрен өстәргә;

13) 44 статьяда:

а) исемендә **"эшкуарлык һәм башка керем китерә торган"** сүзләрен **"керем китерә торган"** сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта:

"эшкуарлык һәм башка" сүзләрен төшереп калдырырга, "эшчәнлеген" сүзеннән соң ", ул нинди максатлар өчен төзелгән булса, шуларга ирешерлек һәм күрсәтелгән максатларга туры килерлек дәрәҗәдә" сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Күрсәтелгән эшчәнлекне дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашыру, әгәр ул федераль законнарга каршы килмәсә, рөхсәт ителә.";

в) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

"$1^{1}$. Казна учреждениесе башка учреждениеләр (шул исәптән мәгариф учреждениеләре), оешмалар эшчәнлегендә өлешле катнашырга, акцияләр, облигацияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга һәм алар буенча керемнәр (дивидендлар, процентлар) алырга хокуклы түгел.";

г) 2 пунктта "яисә җирле үзидарә органнары" сүзләрен төшереп калдырырга, "эшкуарлык" сүзен "керем китерә торган" сүзләренә алмаштырырга;

14) 45 статьяга түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

"16. Урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар студент отрядлары төзергә хокуклы, студент отрядлары дигәндә максатлары укудан буш вакытта икътисадның төрле тармакларында эшләргә теләк белдергән укучыларны вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру эшчәнлеге булган иҗтимагый учреждениеләр яисә иҗтимагый оешмалар дип аңларга кирәк.";

15) 47 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) күрсәтелгән оешмаларда балаларын тоткан өчен алына торган түләү өлешенә әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә компенсация өлешен (алга таба – компенсация) алырга хокуклы.";

16) 52 статьяга түбәндәге эчтәлектә $4^{1}$ пункт өстәргә:

"$4^{1}$. Мәгариф учреждениесенең педагогика хезмәткәрләре өстәмә һөнәри белем бирү программасы эчтәлеге минимумына һәм педагогика хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләү дәрәҗәсенә карата мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән федераль дәүләт таләпләре нигезендә кимендә биш елга бер мәртәбә яңадан һөнәри әзерләнүне яисә квалификациясен күтәрүне узарга хокуклы.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең шушы статья белән башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. 1 статьяның 2 пункты, 3 пунктының "а" пунктчасы, 4 пункты, 7 пунктының "а, б" пунктчалары, 9 пунктының "а, б", "д – ж" пунктчалары, 11 – 13, 16 пунктлары 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 67-ТРЗ